**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Алькеевского сельского
поселения
Азнакаевского муниципального
района

Пер.Советский,44а,
423309 Тел. ( 885592) 37-4-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге
комитеты

Пер.Советский, 44а
Әлкәй авылы, 423309
Тел. (885592) 37-4-23

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22 апрель 2020 ел №13

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга таянып, җирдән файдалану һәм Әлкәй авыл җирлегенең 2020 елның 20 апрелендәге төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә карар бирәм:

1. Әлкәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 22 гыйнварындагы 67 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләүгә керешергә ( 15.11.2016 ел №42, 04.09.2017 ел №62, 03.07.2018 ел №102, 18.03.2019 ел, №128, 18.02.2020 ел, №163 карарлар редакциясендә).

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында

- ТР, Азнакай муниципаль районы, Әлкәй авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:02:020101:323 кадастр номеры булган җир кишәрлеге өчен территориаль Күпфункцияле иҗтимагый - эшлекле зонадан ОД1 дән индивидуаль торак төзелеше зонасына Ж1 күчерү.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай http://pravo.tatarstan.ruмуниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга http://aznakayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык С.З.Зиннурова

Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге башкарма
комитеты карарына 1 нче кушымта
№ 13 22.04.202020 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен үткәрүнең якынча сроклары**

| N | "Әлкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектны әзерләү эшләрен үткәрү тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен оештыру. | 2020 елның II кварталы |
| 2.<br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү, җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволарның кисәтүләренә шәрехләр әзерләү. | 2020 елның II кварталы |
| 3.<br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башлыгына җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын авыл җирлеге Советына раслауга яки кире кагуга кертү һәм аны кабат тапшыру датасын күрсәтеп, эшләп бетерүгә җибәрү турында карар кабул итү өчен җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм аңа карата мәҗбүри кушымталар (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) проектын җибәрү. | 2020 елның II кварталы |